СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

22.03.2021 № 8/1

На № ________ от ____________

**КАРАР**

**Тукай муниципаль районында 2020 ел өчен авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру буенча эш нәтиҗәләре һәм 2021 елга бурычлар турында**

«Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2016 елның 12 гыйнварендәге 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мәгълүматны игътибарга алырга.
2. Район Башкарма комитетына:
- 2020-2022 елларга авылда кече хуҗалыкларны үстерү муниципаль программасының контроль күрсәткечләрен үтәү буенча эзлекле эш алып барырга;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга җитештерелгән һәм эшкәртелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сатуда ярдәм күрсәтергә.
3. Авыл җирлекләре Башлыкларына шәхси ярдәмче хуҗалыкларны саклап калу һәм терлекләрнең баш санын киметмәү буенча эшне контрольдә тотарга тәкъдим итәргә.
4. Тукай районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә тәкъдим итәргә:
- халыктан әзерләүчеләр тарафыннан сатып алына торган продукциянең барлык төрләре өчен сатып алу бәяләре дәрәҗәсенә ай саен мониторинг ясарга;
- Тукай районының крестьян (фермер) хуҗалыклары ассоциациясе, авыл хуҗалыгы кооперативлары һәм шәхси хуҗалыклары белән берлектә авылда кече хуҗалыкларга ярдәм итү буенча дәүләт программаларында катнашу өчен булдыклы фермерларны, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарны сайлап алырга.
5. «Якты юл» («Светлый путь») газетасы редакциясенә халык, фермерлар, авыл хуҗалыгы кооперативлары, авыл җирлегендәге башка эшмәкәрлек рәвешендәге уңай мисалларны даими яктыртырга тәкъдим итәргә.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны социаль сәясәт, инфраструктура үсеше һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М. Камаев